Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_______ Г.Г.Гимадиева

**Әңгәмә "Сак бул интернет"**

**Максат һәм бурычлар** Интернет челтәрендә очрарга мөмкин булган куркыныч әйберләр, сайтлар турында беренчел күзалауларын булдыру. Әти-әниләргә аңлату эшләрен оештыру.

**Катнашучылар** Тәрбияләнүчеләр, тәбияче, әти-әниләр

**Эшчәнлек барышы** Балалар белән рәсемнәр картинкалар карау , интернет челтәрендә очрарга мөмкин булган куркыныч әйберләр, сайтлар турында әңгәмә оештыру

Хәвефсезлек өчен нәрсәләргә ныграк игътибарны юнәлтергә соң?
– Балалар һәм үсмерләр өчен зыянлы төркемнәрне әйтеп үтәм: экстремистик берләшмәләргә яллау, социаль челтәрләрдә "Незнакомый друг", кибер-террор (кибербуллинг, кибермоббинг) яисә "троллинг", киберкараклык, чит кешенең челтәргә керү мөмкинлеге һәм техник чаралар ярдәмендә шәхси мәгълүмат урлау, балигъ булмаганнар турындагы персональ мәгълүматны законсыз рәвештә җыю һәм ачык рәвештә тарату, өлкәннәргә тәгаенләнгән сайтларга керү һәм карау, үсмерләр һәм балаларны суицид хәленә җиткерү, шулай ук хәвефле уеннарга җәлеп итү, балалар йөзен социаль челтәрләргә куюу ("вписки", секстинг) һәм башкалар.

**Нәтиҗә**.Йогаклау Әти-әниләр өчен киңәшләр, буклетлар өләшү. Сайт, төркемнәрнең корбаны булмасын өчен әти-әниләр нинди киңәшләргә колак салырга тиеш?
– Монда, иң беренче чиратта, медиабелемлелек дәрәҗәсен күтәрү зарур. Балагыз социаль челтәрдә икән, сезгә дә виртуаль дөньяда аның белән янәшә торырга кирәк. Сез анда күзәтүче булырга, шул сәбәпле, интернет-этикет осталыгы булдырырга тиешсез. Бу проблема белән күп еллар шөгыльләнү шуны күрсәтә: кызганычка каршы, күпчелек әти-әниләр, мең төрле сәбәп табып, балаларының ни белән мавыкканын белергә дә теләми. Бу очракта алар балалары алдында абруен югалта. Интернет белән эш иткәндә бала кайчан да булса бу хәлләр белән очрашачак. Чөнки аның ышанычына керү һәм файдалану, ялган танышулар булдыру бик җиңел. Балаларны Интернет кагыйдәләренә өйрәтү безнең төп бурыч булып тора. Хәвефсезлек мәсьәләсен хәл итүдә ата-ана контроле функциясе ярдәмгә килә. Ата-ана контроле бихисап ай-ти продуктларда бар һәм корал, яңалыклар, порнография, наркотиклар һәм башка шундый сайтларга балалар тарафыннан керүне чикли. Моннан тыш, нинди веб-сайтларга керүе һәм ачарга тырышуын да контрольдә тота аласыз.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
________Г.Г.Гимадиева

**Хәйрия ярминкәсе: "Ярдәм янәшә"**

**Максат һәм бурычлар** Махсус хәрби операциядә катнашучыларга.Донбасс өлкәсенә ярдәм йөзеннән ярминкә оештыру. Балаларда шәфкатьлелек,ярдәмчеллек,үз эшең ,ярдәм итүең белән горурлану хисләре тәрбияләү

**Катнашучылар** Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр,коллектив

**Эшчәнлек барышы**.Балала белән алдан башкарылачак эшчәнлек.Ярминкә үткәрү өчен балалар белән кул эше(Поделка) ясау.

**1.*Әңгәмә***( Шәфкатлелек, ярдәм итү юллары турында сөйләшү)

**2.*Ярминкә үткәрү***

**3**. Поделкадан җыелган акчаны бергәләшеп санау һәм махсус "Ярдәм янәшә "дигән счетка күчерү өчен конвертка салу һәм тапшыру. Барлык хәйрия ярминкәсендә катнашучыларга рәхмәт әйтү, мактау

**Көтелгән нәтиҗә.** Ярминкә оештырудан җыелган акчаны Ярдәм көткән өлкә счетына күчерү эшен башкару

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
“Олы Кавал “Чишмэкей”
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_________Г.Г.Гимадиева

**Эшчәнлек.Сак бул, куркынычсызлык кагыйдәләрен исеңдә тот”**

**<u>Максат һәм бурычлар</u>** Әйләнә –тирәдәге төрле куркыныч әйберләр, ситуаөияләр турында белемнәрен барлау, яңа белемнәр өстәү
**<u>Катнашучылар</u>** Тәрбияләнүчеләр, тәбияче, әти-әниләр

**<u>Эшчәнлек барышы</u>**
1.Сак бул, куркынычсызлык кагыйдәләрен исеңдә тот” дигән тема буенча картинкалар, буклетлар , плакатардан торган күгәзмә оештыру
2. Проектордан “ Будь осторожен “дигән презентация карау , слайдлар буенча фикер алышу
3. Күргәзмәдәге картинкалар, буклетлар , плакатларны карау
4.Тәрбияченең “Терроризм нәрсә ул? дигән тема буенча сөйләвен тыңлау .
Экстремизм һәм террорчылык очракларына каршы көрәш чаралары һәрдаим алып барыла. Халыкның иминлеген саклау буенча авыл җирлекләре башлыклары, оешма җитәкчеләре белән ныклы элемтә булдырылды. Оешмаларда, мәгариф учреждениеләрендә һәрвакыт өйрәнүләр, әңгәмәләр, рейдлар оештырылып тора. Оешма җитәкчеләренә үз эшчеләре белән, профилактика максатыннан, инструктажлар үткәрү бурычы йөкләнде. Оешма-предприятие биналарының чорма һәм подвалларын даими күзәтеп-тикшереп торуны оештыру бурычы да куелды. Оешмаларга, мәктәпләргә чит кешеләрне бары тик махсус журналларга теркәп, ныклы контрольгә алгач кына үткәрү тәртибе кертелгән. Ишек янында торучы каравыл һәм вахта хезмәте булдырылган. Ләкин әле моның белән генә тукталып калырга ярамый, тагын бер кат искәртеп узар идем, барыбыздан да сизгерлек, уяулык сорала, әти-әниләр дә балаларының нәрсә белән кызыксынуын даими күзәтеп торсыннар иде. Бала нинди интернет сайтларда утыра, кемнәр белән, нинди темаларга аралаша - болар игътибардан читтә калмасын иде. Балалар көтелмәгән хәлләр килеп туганда саклану, үзләрен дөрес тоту кагыйдәләрен әйбәт белергә тиешләр. Безгә хәвефсезлек чараларын тагын да камилләштерергә кирәк. Әледән-әле кабатланып торган хәвефле очраклардан һәркайсыбызга сабак аласы иде, чөнки бу очракта сүз барыбызның да иминлеге хакында бара.
5.Әти-әниләргә буклетлар өләшү
**<u>Көтелгән нәтиҗә</u>** Балаларда куркыныч сиуаөиләр бигәк тә терроризм турында беренчел күзаллау формалаштыру. Әти-әниләргә буклетлар өләшү,уяу булырга чакыру

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
__________Г.Г.Гимадиева

**Тема: Көзге бакчада яшелчәләр җыйнау,саклау урынына урнаштыру**

**Максат һәм бурычлар**

Үз эшеңнә канәгатьләну алу. Хезмәт күнекмәләрен формалаштыру. Яшелчәләргә, җиләк-җимешләргә карата сак караш, аларның витаминнарга бай булуын аңлап, сәламәт тормыш алып бару теләге тәрбияләү.

**Катнашучылар** Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр

**Эшчәнлек барышы.**

1. Хезмәт эшчәнлегенә әзерләнү
2. Тәрбияченең яшелчәләр, аларны карап үстерү,җыйнап кую, саклау эшенең барышы турында балалар белән бергә яңадан искә төшерү.
3. Яшелчәләрне җыеп кәрзиннәргә тутыру
4. Эш беткәч түтәлләрдәге чүпләрне җыйнап түгү,
5. Яшелчәләрне саклык урыннарына урнаштыру

**Көтелгән нәтиҗә.**Балаларның үз хезмәтләреннән канәгатьләнү хисләрен алу.Хезмәт күнекмәләрен формалаштыру.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_____________Г.Г.Гимадиева

**Тема: Батырлар даны мәңгелек**

**Максат.** Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларыбызны, язучыларны искә төшерү, ветераннарга олы ихтирам хисе тәрбияләү;
сугыш афәтенең һәр кеше , һәр гаилә өчен фаҗига булуын төшендерү;
балаларга патриотик тәрбия бирү; тынычлык сөюче шәхес тәрбияләү.
2. Һәйкәл янына төшү.

**Җиһаз.**
1. Бөек Ватан сугышы чорын чагылдырган әдәби әсәрләр күргәзмәсе.
2. Сугыш һәм тыл ветераннары, авылдашларыбыз Советлар Союзы Геройлары хакындагы альбомнар, стенгазета.
3. Плакатлар : "Бөек Җиңүгә - 79 ел", "Алар һәрчак хәтердә", "Батырлар даны мәңгелек".
4. Магнитофон.

Катнашучылар Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче ,авыл мәдәнияте хезмәткәрләре

**Алып баручы.** 1941 елның 22 июне. Якшәмбе көн. Табигать сихри матурлыкка чумган. Иртәнге талгын җилдә бары агачлардагы яшел яфраклар лепердәгән, сандугачлар сайраган тавыш кына ишетелә. Шәһәр кешеләре тыныч йокыда, эшкә барасы юк – ял көне. Авыл кешеләре инде аяк өстендә, көтүләрен куып, башка дөнья мәшәкатьләре белән мәшгуль.

Һич көтмәгәндә немец самолетлары тыныч шәһәрләр, авыллар өстенә бомбалар яудыра башлый.

*("Изге сугыш"җыры яңгырый.)*

. Сугыш... Күпме ачы күз яшен, кайгы-хәсрәтне үз эченә алган бу шомлы сүз! Ул ничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме сабыйларны ятим иткән, аналарны тол калдырган....

Сугыш... Меңләгән шәһәрләр җимерелгән. Җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән.

. Явыз дошман килгән ил өстенә,
Ил байлыгын талап җыярга.
Алып килгән канлы палачларын
Халкыбызның канын коярга.

Чыннан да, Бөек Ватан сугышы чоры совет халкы өчен зур сынау еллары була. Сугышның беренче көннәреннән үк русы, татары, удмурты, чувашы туган илен - Ватанын сакларга күтәрелә

Дәвамы Сценарий буенча,...

**Көтелгән нәтиҗә.** Балаларның үткән сугыш еллары турында, авылдашларның ул еллардагы батырлыгы турында күзаллауларын формалаштыру

Төзеде тәрбияче. Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_____________Г.Г.Гимадиева

**Экскурсия: Авыл китапханәсе белән танышу**

**Максат һәм бурычлар** Китапханә китапханәче хезмәте белән танышу.Китапларга карата уңай караш тәрбияләү

**Катнашучылар** Тәрбияләнүчеләр, тәбияче, эти-әниләр

**Эшчәнлек барышы**

1. Китапханәгә төшү

2.Китапханә белән танышу

3.Китапханәченең китаплап ,аларны саклап тоту турында сөйләвен тыңлау

4. Балаларның белгән шигырьләрен сөйләвен тыңлау

5. "Булсаж зирәк,әйт тизрәк "дигән сорау-җаваплар уенын уйнау

**Көтелгән нәтиҗә** Балаларда китапларга,аларга карата уңай караш тәрбияләү. Китапханәче һөнәре турында күзаллауларын ныгыту

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_________Г.Г.Гимадиева

**Эковесна2024" икеайлыгы акциясендә катнашу**

**Максат һәм бурычлар** Эковесна2024" икеайлыгы акциясендә катнашу Балаларга экологик тәрбия бирү. Туган як табигатенә карата мәхәббәт тәрбияләү

**Эшчәнлек барышы** 2 ай дәвамында Республика күләм акциядә катнашу ВК сайтына куеп үзэшчәнлегебезне күрсәтә бару

**Катнашучылар** Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр, экологик инспекторлар

**Көтелгән нәтиҗә** Экологик белемнәре арту, туган якка ,аны табигатенә карата мәхәббәт уяту

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
“Олы Кавал “Чишмэкей” балалар бакчасы МББМБУ мөдире
_____________Г.Г.Гимадиева

**Татар халык ризыклары- табын күрке**.

**Максат**.
-Кунак каршы алуга хөрмәт, игътирам белән карарга өйрәтү;
-Кыстыбый пешерү серләрен өйрәтү;
-Пешекче хезмәтенә карата кызыксыну хөрмәт тәрбияләү;
- милли гореф –гадәтләрне, әхлак кагыйдәләрен өйрәтү;
-Бергәләшеп, тату эшләү күнекмәләрен ныгыту.
**Җиһазлар.** Кирәкле савыт-сабалар, ризыклар,пешекчеләр кия торган махсус киемнәр.
**Катнашучылар.** Катнаш төркем балалары,тәрбияче, кече тәрбияче, пешекче, әти-әниләр
***Эшчәнлек барышы***
**Тәрбияче.**Балалар зур сөенеч бар. Бүген күршедә яшәүче ак әбиебез кунакка керергә вәгъдә бирде. Әйдәгез, нишлибез, кунакны ничек каршы алабыз?
**Балалар җавабы**. Өебезне җыештырырга, бүләк әзерләргә, чәй куярга, тәмле ризык пешерергә, матур күлмәкләр киеп куярга кирәк.
**Тәрбияче.** Балалар алай булгач, әйдә, эшкә тотыныйк. Кунакны сыйлар өчен нинди милли ризык әзерлик икән?
**Балалар**. Бәлеш, кош теле, бавырсак, чәк-чәк, кыстыбый.
**Тәрбияче**. Әйдәгез, кыстыбый пешерәбез .
**Балалар**.Бик әйбәт, әйдәгез, пешерәбез.
**Тәрбияче.**Кыстыбый бик тәмле һәм туклыклы, шул ук вакытта әзерләргә артык катлаулы булмаган татар милли ашы. Кайбер җирдә кыстыбыйны **күзикмәк, якмыш** та диләр. Гадәттә аны төче камырдан әзерлиләр. Кыстыбый эченә төйгән бәрәңге, тары боткасы, төйгән киндер орлыгы, мәк һ.б. салалар.
*Әзерләү тәртибен аңлатып үтәм, тыңлагыз, исегездә калдырыгыз*
Бит каты итмәчә генә төче камыр басалар да, бераз тоткач, 75 әр г лы кисәкләргә бүлеп, юка гына итеп җәяләр, җәемнәрне кызган табада, май сөртмичә генә, башта бер, аннары икенче ягын әйләндереп пешереп алалар, суынмасын һәм катып китмәсен өчен, берсе өстенә берсен өеп, тастымал белән каплап куялар. Чөнки суынса, урталай бөкләгәндә сына.
Кыстыбый эченә салу өчен, бәрәңге пешереп, кайнар килеш төяләр, кайнар сөт, сары май, майда кыздырылган суган салып болгаталар.
Әзер җәемнең яртысына бәрәңге боламыгы ягып, тиз генә икенче ягы белән каплыйлар. Кыстыбыйны, эрегән май белән майлап, табынга кайнар килеш бирәләр.
*1 кыстыбыйга: 75 г камыр, 100 г бәрәңге, 20 г суган, 20 г сөт, эченә салырг*

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
“Олы Кавал “Чишмэкей”
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
____________Г.Г.Гимадиева

## ”Үткәнәрне барлыйбыз, киләчәккә атлыйбыз”

**Максат.** Балаларга халкыбызныж гореф-гадәтләре, йолалары көнкүреш әйберләре турында күзаллауларын үстерү Туган телгә ,мәдәнияткә карата кызыксыну уяту

Катнашучылыр. Тәрбияләнүчеләр, тәрбиячеләр

**Эшчәнлек барышы**.

1. Алдан эшләнәсе эш Һәр гаиләгәГаилә шәҗәрәсен “төзү.
2. Шәҗәрә турында әңгәмә
3. Милли киемнәр”күргәзмәсен карау
4. Чигүле селгеләр, чаршаулар,пәрдә кашагалары белән танышу
5. Милли татар бизәкләре белән танышу

**Көтелгән нәтиҗә**

Татар халкының төрле өй бизәү әйберләренә , чигү үрнәкләренә кызыксыну уяту .Гаилә шәҗәрәсе турында белүләренә ирешү һ.б.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей" балалар бакчасы МББМБУ мөдире
____________Г.Г.Гимадиева

**Без Тукай варислары" бәйгесе**

**Максат һәм бурычлар** Республика күләм бәйгедә катнашу өчен Иң уңышлы дип саналган "Карлыгач" шигырен бәйгедә катнашу өчен җибәрү

**Эшчәнлек барышы** .Балалар арасында сайлап алу турын үткәрү. Бәйрәм рухын тудыру

**Катнашучылар** Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр

**Көтелгән нәтиҗә** Балаларда матур сөйләмгә мәхәббәт уяту, сәнгатьле сөйләм формалаштыру

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_______________ Г.Г.Гимадиева

**"Яшел ут-2024" бәйгесе**

**Максат** Республика күләм"Яшел ут-2024" бәйгесендә катнашу өчен план төзү. Төрле эшчәнлекләр үткәрү Бу эшчәнлекләрдә әти-әниләрнең актив катнашуына ирешү

Эшчәнлекләр

Буклетлар тарату "Юл йөрү кагыйдәләрен үтәгез!"

**Акцияләр:**

1. "Саклык каешын эләктер"

2: "Фликерлар-гомерне саклый"

3.Интеграль эшчәнлек "Гаилә-имин юл күрсәтүче!"

4.Эшчәнлек "Светофорик" отряды-иминлек сагында"

**Көтелгән нәтиҗә**. Балаларда юл йөрү кагыйдәлрен белү аны үтәү зарурлыгын күңеләренә сеңдерү. Әти-әниләрнең балаларына юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү кирәклегенә җитди карауларына ирешү.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
“Олы Кавал “Чишмэкей”
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_________Г.Г.Гимадиева

**Батыр егет-ил күрке**

Катнашучылар Тәрбияләнүчеләр, тәбияче

**Максат.** Балаларда туган илгә, аның иминлеге сагында торучы солдатларга карат хөрмәт , горурлык хисләре тәрбияләү. Туган илне саклаучылар булучылар буласылары килү теләген үстерү.

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Хәерле көн , дусларым. Бүген бездә кунакта авылыбызның хөрмәтле кешесе, моннан бер ел элек **махсус хәрби операциягә** -СВО га үз теләге белән хезмәт итәргә киткән, хәзергесе вакытта кыска ялга кайткан Газиз абыегыз(Исәнмесез).Әйдәгез сүзне Сезгә бирик әле,Газиз,рәхим итегез. (сценарий буенча дәвам итү)

**Көтелгән нәтиҗә**

Батыр егет-ил күрке! темасына түгәрәк өстәл узды. Бу чарага махсус хәрби операциядән кыска вакытлы ялга кайткан яугир чакырылган иде. Ватанпәрвәрлек рухы белән сугарылган чара җылы атмосферада узды. Очрашу барышында яугир балаларга хәрби хезмәт, яшәү шартлары, солдатлар арасында командалык рухы һәм дуслык турында сөйләде. Туган илне яклау һәрбер ир-егетнең бурычы булуын билгеләде. Әлеге очрашуга җыелган балалар һәм бакча коллективы аңа изге теләкләрен җиткерде һәм, исән-имин әйләнеп кайткач, тагын шундый очрашу оештырырга килештеләр.

Әйе, без барыбыз да махсус хәрби операциянең тизрәк тәмамлануын, барлык ир-егетләребезнең туган якларына исән-имин һәм җиңү белән әйләнеп кайтуын телибез. Тыныч тормышта да батырлыкка урын җитәрлек.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей" балалар бакчасы МББМБУ мөдире
___________Г.Г.Гимадиева

**"Татар сүзе"бәйгесе**

**Максат һәм бурычлар** Республика күләм бәйгедә катнашу өчен Иң уңышлы дип саналган шигырҗне бәйгедә катнашу өчен җибәрү

**Эшчәнлек барышы** .Балалар арасында сайлап алу турын үткәрү. Бәйрәм рухын тудыру

**Катнашучылар** Тәрбияләнүчеләр, тәрбияче, әти-әниләр

**Көтелгән нәтиҗә** Балаларда матур сөйләмгә мәхәббәт уяту, сәнгатьле сөйләм формалаштыру

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү  муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
“Олы Кавал “Чишмэкей”
балалар бакчасы  МББМБУ
мөдире
_____________Г.Г.Гимадиева

**Әкиятләр иленә сәяхәт.**

**“Тылсымлы чемодан” бәйгесендә катнашу**

**Максат** Әти-әниләр арасында “Тылсымлы чемодан”дип аталган бәйгедә катнаштыру  иң матур ,эчтәлекле дип табылган эшне Республикакүләм бәйгегә җибәрү

**Эшчәнлек барышы**.Бәйгегә дип эшләнгән чемодандагы әкият персонажлары белән балалар белән әкиятәр сыйләү “Өч Кыз, “Йомры икмәк”,”Су анасы” һ.б әкиятләр

**Көтелгән нәтиҗә**. Балаларда әкиятләргә карата кызыксыну уяту,сөйләм телен баету.

Төзеде тәрбияче  Яруллина Ф.Н.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

Расланды:
"Олы Кавал "Чишмэкей"
балалар бакчасы МББМБУ
мөдире
_____________Г.Г.Гимадиева

**"Әбиемдә кунакта" күңел чарасын оештыру**

**Максат**. Милли ризыклар, табын әдабе, әхлак кагыйдәләре йолалар турында белемнәрне киңәйтү

Эшчәнлек барышы ***Гөлҗамал апа*** *керә.* Әссәламегаләйкем, балалар.

**Балалар.** Исәнмесез, Гөлҗамал апа, түрдән узыгыз,без сезне көттек.

**Гөлҗамал апа**. Кунак киләсен каян белдегез, мәчегез битен юдымы әллә?

**Тәрбияче**. Ник алай дисез, бездә мәче юк бит.

**Гөлҗамал әби**.Бу бит халык сынамышы. Тыңлагыз алай булгач, тагын сынамышлар әйтәм

-Мендәр идәнгә ишелеп төшсә-кунак килүен көт;

-Мәче битен юса-кунак килә;

-Самовар җырласа-кунак килә.

**Балалар** Гөлҗамал әби, әйдә, түрдән чәй табына узыгыз.

**Тәрбияче.** Гөлҗамал апа, балаларыбыз син килә диеп, әй тырыштылыр, әй тырыштылар.

**Гөлҗамал әби**. Рәхмәт, әйдәгез, табын янына утырганчы сезгә әйтәсе сүзәрем бар. Исегездә калдырыгыз яме.

-Әти-әнидән алда өстәл янына утырырга ашыкма,

-Алдыңа куелган ризыкны ашыкмыйчан гына аша,

-ипине сындарып кына ал, валчыгын койма,

-буең җитмәгән ризыкка үрелмә, сорап кына ал.

- өстәл яныннан рәхмәтеңне әйтеп кит.

- алдыңа тастымал куй, аңа авызыңны , кулыңны сөртмә

- авыз кырыйларын сертү өчен кәгазъ салфеткалар куллан.

**Балалар**. Бик зур рәхмәт,тәртипле булырга тырышырбыз.

**Тәрбияче.** Ягез, өстәл артында дөрес туклану кагыйдәләре турында тагын нәрсәләр беләсез.

**Балалар.**

- Авызда ризык булганда сөйләшергә ярамый,

-Авызны чапылдатып, кашыкны тәлинкәгә бәрә-бәрә тавыш чыгарып ашарга ярамый;

-Терсәкләрне өстәл өстенә җәеп, аякларны селкетеп утырырга ярамый.

**Тәрбияче.**Үгет-нәсыйхәтләрең өчен зур рәхмәт. (Балалар Гөлҗамал апаны өстәл артына утырталар, аннан соң үзләре утыралар, алларына тастымал ябалар,сыйланалар )

**Гөлҗамал әби**. Иии, бик тәмле булды, рәхмәт балалар. Кем пешерде соң бу кыстыбыйны?

**Балалар** Без пешедек, пешерергә пешекчебез Гөлшат апа өйрәтте.

Төзеде тәрбияче Яруллина Ф.Н.